**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 19 мартындагы 777 номерлы карары**

**Казан шәһәре Вахитов районының Гоголь урамы һәм**
**Подлужная урамы буенча ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитут характеристикасы:

- йогынты ясала торган өлкә мәйданы – 974 кв.м;
- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары – 16:50:010603:37, 16:50:010603:18, 16:50:010603:130;
- урнашу урыны: Казан шәһәре, Вахитов районы, Гоголь урамы һәм Подлужная урамы;
- билгеләү максаты: җәяү һәм транспортта узуны тәэмин итү өчен;
- билгеләү вакыты: вакыты чикләнмәгән;

1.2. гариза бирүче: «Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесе;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы.

2. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

3. Әлеге карарга 2 номерлы кушымтадан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

5. «Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесенә тәкъдим итәргә:

5.1. Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының 2023 елның 11 маендагы 1311 номерлы «Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән федераль әһәмияткә ия «Казан кремле ансамбле», XV гасыр – XX гасырның беренче чиреге (Татарстан Республикасы (Татарстан) мәдәни мирас объектын саклау зоналары чикләрен, җирләрдән файдалануның махсус режимнарын һәм әлеге зоналар территорияләре чикләрендә шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләрне раслау турында»гы әмере белән каралган чикләүләрне үтәргә;

5.2. Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2024 елның 28 декабрендәге 749-П номерлы «Казан шәһәренең төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлеге территориясе чикләрен һәм сак предметын раслау турында»гы әмере нигезендә чикләүләрне үтәргә;

5.3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 февралендәге 79 номерлы карары нигезендә чикләүләрне үтәргә. Аның буенча территория «Казан шәһәре тарихи үзәгенең XI – XVIII гасырлар мәдәни катламы» истәлекле урыны рәвешендә федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә урнашкан;


5.4. истәлекле урыннар территориясе чикләрендә проектлауга, төзүгә һәм хуҗалык эшчәнлегенә карата 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында»гы федераль закон һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2010 елның 1 апрелендәге 183 номерлы «Истәлекле урын территориясеннән файдалану характеры, әлеге территориядән файдалануга чикләүләр һәм Казан шәһәренең истәлекле урыннары территориясендә хуҗалык эшчәнлегенә, проектлауга һәм төзүгә таләпләр турында нигезләмәне раслау хакында»гы әмере белән билгеләнгән таләпләрне үтәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 19 мартындагы
777 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Вахитов районының Гоголь урамы һәм Подлужная урамы буенча ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**




Масштаб: 1:1500
Координаталар системасы: МСК-16

| Шартлы билгеләр: | |
|---|---|
| | Ачык сервитутлар (Проектлана торган) |
| | Җир кишәрлекләре |

| | |
|---|---|
| 16:50:010603 | кадастр кварталы |
| 16:50:010603:37, 16:50:010603:18, 16:50:010603:130 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |

___________________________